Тәрбия сәгате.

# Тема: Хокуклар һәм бурычлар.

**Максат:** 1)Укучыларга конституцион хокуклар һәм бурычлар турында белемнәр бирү;

2)Үз хокукларыңны курыкмыйча яклый белү сәләтен үстерү;

3)Гаделлек, миһербанлылык, шәфкатьлелек сыйфатлары тәрбиләү.

***- Нәрсә ул хокук?***

***Хокук ул*** **– дәүләт тарафыннан урнаштырылган һәм үтәлүе дәүләт көче белән тәэмин ителә торган, һәркем өчен мәҗбүри тәртип нормалары системасы.**

***- Ә нәрсә ул хокук бозу?***

**Хокук бозу ул – закон тарафыннан саклана торган иҗтимагый мөнәсәбәтләргә кул сузучы кешенең иҗтимагый куркыныч, хокукка каршы юнәлтелгән гамәле.**

## *Хокук бозган өчен нәрсә карала?*

Юридик җаваплылык – хокук бозучыга карата закон тарафыннан төгәл билгеләнгән процессуаль тәртип кысаларында вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан дәүләтнең мәҗбүр итү чаралары күрсәтелгән хокукый нормалар санкцияләрен куллану.

**Конституция – Дәүләтнең Төп Законы. Ул җәмгыятьнең сәяси яшәү формасын, дәүләт хакимияте органнары системасын юридик яктан рәсмиләштерә, аларның формалаштыру тәртибен һәм эшчәнлек ысулларын билгели, кеше һәм гражданның хокукларын, ирекләрен һәм бурычларын беркетә.**

-*Россия Федерациясе Конституциясе кайчан кабул ителгән?*

**12 декабрь, 1993 ел,**

***-Татарстан Конституциясе кайчан кабул ителгән?***

**6 ноябрь, 1992 ел**

Административ кодексы

Гаилә кодексы

Конституция

Гражданлык кодексы

Хезмәт кодексы

Җир кодексы

Җинаятьчелек кодексы

- ***Укучылар, сезнең нинди хокукларыгыз бар?***

-Яшәүгә хокук;
-Иреккә һәм шәхси кагылгысызлыкка хокук;
-Яклануга хокук;
-Торакка хокукы;
-Социаль тәэмин ителүгә хокук;
-Сәламәтлекне саклауга һәм медицина ярдәменә хокук;
-Белем алуга хокук.

1989 елның 20 ноябрендә БМОның Генераль Ассамблеясы Бала хокуклары турындагы Конвенция кабул итә.

-Нәрсә ул бурыч?

-Безнең нинди конституцион бурычлар бар?